Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Калинино авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Сосновая, Липовая, Березовая урамнарында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

7 ноябрь 2024 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы нигезендә, 2024 елның 7 ноябрендә 18 сәгать 30 минутта узган «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Калинино авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Сосновая, Липовая, Березовая урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- урамнарны яктырту буенча эшләр башкару белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 162 (йөз алтмыш ике) катнашучы кертелгән, 82 (туксан ике) кеше гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан, бу 50, 6 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 82 (сиксән ике) катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Калинино авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Сосновая, Липовая, Березовая урамнарында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Калинино авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә – Сосновая, Липовая, Березовая урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- урамнарны яктырту буенча эшләр;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авыл җирлеге, Зур Кызыл урамы, 113 А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендында, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнашттыру юлы белән халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.А. Хабибуллин